**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№9300**
**10.09.2026**

Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр транспорты» МУПка транспорт чаралары салоннарында сайлау алды басма агитация материалларын түләүсез урнаштыруны килештерү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 54 статьясындагы 8 пункты, «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар турында» 2014 елның 22 февралендәге 20-ФЗ номерлы Федераль законның 68 статьясындагы 10 өлеше, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр транспорты» МУПка IX чакырылыш Дәүләт Думасы депутатларын сайлаулар буенча сайлау кампаниясен үткәрү чорына түбәндәге шартларда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шәһәр җир өсте электр һәм автомобиль транспортында даими муниципаль маршрутлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган транспорт чаралары салоннарында сайлау алды басма агитация материалларын түләүсез урнаштыруны килештерергә:

| Агитация материалының форматы, 1 транспорт берәмлегенә агитация материалларының саны | Транспорт берәмлекләре саны | Урнаштыру урыны | Урнаштыру срогы |
|---|---|---|---|
| А3 форматы 3 нөсхәдән артык түгел<br>А4 форматы 1 нөсхә | 140 берәмлек автобус<br>60 берәмлек трамвай | автобусның һәм (яки) трамвайның ян һәм (яки) арткы пыяласы | 18.09.2026 00:00 гә кадәр |

2. Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәр транспорты» МУП генераль директоры И.Н. Гыйззәтуллинга тәэмин итәргә:

1) теркәлгән кандидатлардан басма агитация материалларын урнаштыруга заявкалар кабул итүне һәм агитация материалларын бертигез шартларда урнаштыруны;

2) сайлау алды басма агитация материалларын транспорт чараларыннан 2026 елның 18 сентябре 00:00 сәгатькә кадәр алуны.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Р.Г. Гозәеровка, Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов